| | | |
|---|---|---|
| **АКТАНЫШСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**<br>423740,село Актаныш, проспект Ленина,дом 58 ,тел.3-15-99. | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**<br>423740, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт. Тел.3-15-99 |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«05» июнь 2019 ел** **№10**

2019 елгы су коену сезоны чорында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегендәге ачык сулыкларда коенуны тыю турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының “Актаныш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 03.06.2019 ел, №ПР-125 санлы карары белән, Актаныш авыл җирлеге территориясендә пляжлар һәм суда массакүләм ял итү урыннары булмау сәбәпле, гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклау максатларында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елгы су коену сезоны чорында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге территориясендә урнашкан ачык сулыкларда коенуны тыярга.
2. Су коену сезоны дәвамында җирлек территориясендә ачык сулыкларда коенуны тыю турында халык белән аңлату эшләре һәм балаларны махсус контрольдә тоту кирәклеге турында белешмәлекләр өләшеп аңлату эшләре алып барырга.
3. Балаларны караучысыз тоту һәм өлкән кешеләр тарафыннан контрольдә тоту рөхсәт ителгән гаиләләрне аерым контрольгә алырга, мондый гаиләләр белән шәхси профилактик эш алып барырга, ата-аналарга кул куйдырып коенуны тыю турында белешмәлекләр тапшырырга.
4. Ачык сулыкларда су коенуны тыю турында аншлаглар урнаштырырга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында “Актаныш авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.
6. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Актаныш авыл Башкарма комитеты җитәкчесе И.Ш. Шәрәпов